КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 11 июль г.Казань № 565

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 31 октябрь, 965 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1262 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Югары белем бирүнең мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмалары һәм Татарстан Республикасының өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне.»;

5 нче пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче карарының гамәле 2018 елның 1 сентябреннән – гомуми белем бирү оешмаларына, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына, һөнәри белем бирү оешмаларына һәм өстәмә белем бирүче мәгариф

оешмаларына, 2019 елның 1 сентябреннән югары белем бирүнең мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларына һәм Татарстан Республикасының өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларына кагылмый.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларының эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

II бүлектә:

1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Югары белем бирүнең мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларының эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләре өчен база окладына карата тармак өстенлеге коэффициенты 1,35 күләмендә кулланыла.

Әлеге коэффициентны база окладына карата куллану яңа база оклады барлыкка китерә, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрне исәпләгәндә исәпкә алына.»;

әлеге карарга Югары белем бирүнең мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмалары һәм Татарстан Республикасының өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне (карарга теркәлә) өстәргә.

2. Бу карарның гамәле 2019 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин